**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

«07» июль 2021 ел Иштирәк авылы №13/1

«Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2017 елның 26 сентябрендәге «Җир салымы турында» 25/4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 5, 394, 397 статьялары, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2017 елның 26 сентябрендәге «Җир салымы турында» 25/4 номерлы карарына (2017 елның 28 декабрендәге 30/2, 2018 елның 14 сентябрендәге 38/4, 2018 елның 30 октябрендәге 40/3, 2019 елның 8 ноябрендәге 52/2, 2020 елның 27 февралендәге 55/2, 2021 елның 17 мартындагы 9/1 номерлы каралар үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктның беренче абзацында «2018 елга» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Салым түләүчеләр – оешмалар өчен хисап чоры дип календарь елның беренче, икенче һәм өченче кварталлары танылa, дип билгеләргә.

Салым түләүчеләр – оешмалар өчен салым түләү җир кишәрлегенең кадастр бәясенең 1/4 процент өлешенең тиешле салым ставкасының 1/4 күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла.».

2. Әлеге карарның 1 пункты 1 пунктчасы рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә карата 2019 елның 1 гыйнвареннан гамәлдә була.

Әлеге карарның 1 пункты 2 пунктчасы рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да иртәрәк булмаган һәм 2022 елның 1 гыйнвареннан дә иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе Г.С. Гарифуллина